ГЛАВА АБСАЛЯМОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Молодежная, д.2,
с.Абсалямово, 423957

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӘБСӘЛӘМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Яшьләр урамы, 2 йорт,
Әбсәләм авылы, 423957

Тел.:(85593) 4-26-79, факс:4-26-79, e-mail: Absal..Utz@tatar.mailto:adm.jutaza@tatar.ruru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 2** **9 ноябрь 2020 ел**

Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм торак пунктында 2021 елда үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, 2019 елның 17 июлендәге 8 санлы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге Советы карары белән расланган Уставның 14 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы "Әбсәләм авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге башлыгы

К А Р А Р  Б И Р Ә:

1. Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы, Әбсәләм авылы, Совет урамы, 50Г йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасы янында 2021 нче елда Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм торак пунктында 2020 нче елның 21 ноябрендә 10 сәгатьтә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегенә керүче Әбсәләм торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигълык яшенә җиткән гражданнардан 2021 елда 400 (дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга сез ризамы:

- Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм торак пунктындагы Совет урамына асфальт юл түшәү (сатып алу, ташу, җәю, эшләү, килешү өчен түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әбсәләм авыл җирлеге башкарма комитеты халык җыенына әзерлек һәм аны үткәрүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Әбсәләм авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru.

5. Әлеге карар рәсми халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Әбсәләм авыл җирлеге башлыгы Г.В. Кубашева